ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

с.Верх.Тат.Майна

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**09.11.2023** **№ 21**

**«Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2012 елның 8 ноябрендәге 14а номерлы Майна авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контроль буенча чаралар үткәргәндә үтәлә торган мәҗбүри таләпләр булган башкарма хакимиятнең федераль органнарының норматив хокукый актларын гамәлдән чыгару турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты

карар бирә:

1.Майна авыл җирлеге Башкарма комитетының 2012 елның 8 ноябрендәге 14а номерлы «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» карарына 1 нче кушымтаның 4 нче «Сатучыларга таләпләр» бүлегендә сүзләр:
«-19.01.1998 елгы 55 номерлы Аерым төр товарларны сату таләпләрен һәм кагыйдәләрен үтәргә,» төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.
3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Майна авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **ЯД.Иванов**